Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Урман Кәләй авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

6 май 2019 ел № 6

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Урман Кәләй авылы башкарма
комитеты карарларының
үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Урман Кәләй авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авылы башкарма комитетының “Вәкаләтләрнең бер өлешен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында”гы 2011 елның 18 маендагы 9а номерлы карары кушымтасының 1,2,3 пунктларын үз кечен югалткан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авылы башкарма комитетының 2012 елның 10 сентябрендәге « Урман Кәләй авылы башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү хакында 2011 елның 18 маендагы 9а номерлы” карары уз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, 38б йорты; Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Урман Кәләй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитекчесе Л.Н. Фәләхиев